КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 октябрь г.Казань № 892

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән расланган Электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 декабрь, 1402 нче, 2023 ел, 27 апрель, 531 нче, 2023 ел, 13 сентябрь, 1120 нче,

2023 ел, 20 октябрь, 1333 нче, 2023 ел, 15 декабрь, 1614 нче, 2024 ел, 23 май, 358 нче, 2024 ел, 16 август, 665 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга яки җитештерүгә һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.8. Сайлап алуда катнашучы бер сайлап алу барышында заряд җыю инфраструктурасының төрле объектларына карата берничә тәкъдим (заявка) бирергә мөмкин. Сайлап алуның бер катнашучысыннан тәкъдимнәр (заявкалар) керү көнендә чират тәртибендә «Электрон бюджет» системасында теркәү номерын бирү белән теркәлә. Шул ук вакытта берничә тәкъдим (заявка) биргән сайлап алуда катнашучы белән, техник мөмкинлек булганда, сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче һәм субсидия алучы итеп билгеләнгән барлык тәкъдимнәргә (заявкаларга) карата субсидия бирү турында бер килешү төзелә.»;

3.4 пунктның 3.4.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) карау сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң 15 эш көне эчендә комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин